ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЭШЕР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423357, Иске Кэшер авылы, Комсомол ур. 4а,
тел. (885559)4-86-36 E –mail : Sksr.sar@.tatar.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТА
СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГ
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423357, с. Старый Кашир, ул. Комсомола, 4а,
тел. (885559) 4-86-36 E-mail: Sksr.sar@.tatar..

РЕШЕНИЕ КАРАР

«18» марта 2019 года № 10

Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр мониторингын үткәрү буенча эшчәнлеген камиллəштерү максатында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кэшер авыл жирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кэшер авыл жирлеге Советы карар бирә:

1. Карарга теркәлгән “Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне” расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларның законнарга, муниципаль берәмлекләрнең уставларына туры килүен системалы рәвештә контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында мониторинг үткәрүне тәэмин итә торган муниципаль норматив хокукый актлар кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Иске Кэшер авыл жирлеге Советына йөкләргә.

6. Әлеге карар, рәсми игълан ителгән көненнән ун көн узгач, үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Иске Кэшер авыл жирлеге Советы рәисе Р.Н.Давлетзянов